**Татар хатыны ниләр күрми...**

(бер эзләнү тарихыннан)

Бөек Ватан сугышында Балык Бистәсе районы Югары Тегермәнлек авылыннан 599 кеше катнаша, шуларның 413 һәлак була. 1975 елның 9 маенда ачылган “Сугышчан һәм хезмәт даны” мәктәп музеенда батыр сугышчылар турында бик күп төрле мәгълүматлар тупланган. Аларга багышланган альбомнар, стендлар, рефератлар әлеге музейда урын алган.

Авыр сугыш еллары турында күп материал тупланса да, кызганычка каршы, өйрәнелмәгән тарихи битләребез дә бар. Шулар арасында икенче Бөек Ватан сугышында катнашып әсирлеккә эләгеп һәлак булган һәм исән кайтучылар. Совет чорында фашист концлагерьларын үткән гражданнарыбыз сугыш каһарманнары булып исәпләнмәде, шуңа күрәдер дә инде мәктәп музеенда алар турында мәгълүматлар аз. Без ничек булса да, мондый авылдашларыбызне барлап тарихи битләргә язып калдырырга тиеш дип уйлыйм.

Югары Тегермәнлек авылыннан хатын-кызлар арасында сугышта катнашкан кешенең барлыгын белә идем инде. Ләкин кулда документ булмагач моны раслап булмады. [www.obd-memorial.ru](http://www.obd-memorial.ru) сайтында авыл исемен кертеп эзләгәндә әсирлектән азат ителгән Савник Шакура исемле авылдашка тап булдым. Россия Федерациясенең үзәк архивының **р-9526 фондының 6 тасвирламасының 1142 эш кенәгәсеннә**н алып сайтка урнаштырылган документта фамилияне Савина дип укырга була, ягъни Сафина инде татарча.... Архив мәгълүматының беренче битенең башында болай дип язылган: “Список граждан СССР уезжающие на родину из Норвегии через сборный пункт Нарвик 1». Бу исемлек 8 баганага бүленгән. Беренчесендә номер, икенчесендә фамилия исем, өченчесендә хәрби дәрәҗә һәм армиядә хезмәт итүе, дүртенчесендә туган елы, ае, көне, бишенче баганада милләте, алтынчыда гаилә хәле, җиденчесендә туган урыны һәм дә инде сигезенчесендә соңгы яшәү урыны. Шәкүрә әби турында шлеге документтан түбәндәгеләрне белергә мөмкин: 1) ул 798 номер астында язылган, 2) Савина Шакура, 3) хәрби дәрәҗәсе юк, армиядә хезмәт итүе китерелмәгән, 4) 1921 елның 13 октябрендә туган дип язылган, 5) милләте татар, 6) кияүдә түгел 7) Татарстан АССРның Кызыл Йолдыз районының Югары Тегермәнлек (Тимерлек) авылында туган, 8) әсирлеккә төшкәнче Ленинград өлкәсендә яшәгәнлеге билгеле. Кызганычка сканер аша чыгарылып китерелгән бу документны электрон формада зурайтып кына укып була. Кәгазьгә бастырып алгач күбесен укып булмый. Яшәгән урыны да Ленинград өлкәсенең кайсы төбәгендә икәнлеген төгәл укый алмадым. Ләкин торган йорты Лысая, 4 дип китерелгән. Кулга документ кергәч Шәкүрә әби турында материаллар җыя башладык. Миңа бу эштә укучым Касыймова Миләүшә дә булышты.

Татарстан Республикасы милли архивының **6901 фондның 1 тасвирламаның 12 нче эш кенәгәсендә** сакланган 1938 – 1939 елларга караган хуҗалык кенәгәсендә Шәкүрә әбинең гаиләсе 106 номер белән

китерелгән. Аның әтисе Рәхимов Сафа 1892 елда туган, 1932 елның 10 июнендә колхозга кергән. Хатыны Мәрфуга (Шәкүрә әбинең уги әнисе) 1904 елгы, аларның 1 сыерлары, 3 сарыклары булуы турында язылган. Йортлары 1927 елда төзелгәне билгеле, 1926 елда абзар кура җиткергәннәр, 1927 елда мунча салганнар, ә 1928 елда келәт һәм синнек төзегәннәр. Күреп торганыбызча, Шәкүрә әбинең гаиләсе яхшы тормышта яшәгәннәр, ләкин үги ана белән яшәү авыр булгандыр күрәмсең. 1934 елда Оркыя исемле уги сеңлесе, 1935 елда Нәсимә исемле үги сеңлесе тугач, Шәкүрә әбигә бу гаиләдә тору тагы да авырлашкан. Миңа моны шулай ук авылдашларым да раслады.

Шафигуллина Шәмсенур Шәкүрә әби турында әз белә. Аның сүзләре буенча, Шәкүрә тыйнак кыз булган, үги әнисенә бик ярдәм иткән. Үги әнисе әбиемнең әнисе белән дус булганнар, еш кына кунакка йөрешкәннәр. "Шәкүрә әбинең йөзен һәм холкын белмим, һәм кайда кияүгә чыкканын да белмим" ди ул.

Шәйхиева Шәһәрзифа апа Шәкүрә әбине күз яшьләре белән искә алып сөйлИ. "Зур гәүдәле иде, Шәкүрә апа, сугыштан соң без күрше авылларга икмәк алып кайтырга, утын кисәргә бара идек, шунда Шәкүрә апа иң беренче бара иде, кыш көне, безнең гәүдәләр кечкенә булганга, тирән кардан баруы читен булганга, Шәкүрә апа: "Үзем атлыйм, беренче кызлар", дия иде. Җитди кеше иде ул, без аннан курка да идек әле. Озак эшләмәдек без аның белән, аннары ул Балтачка кияүгә чыкты. Аның Балык Бистәсендә кызларында торганын ишеткәч бик барасым килгән иде, саулыклар ирек бирмәде", диде Шәһәрзифа апа.

Шәйхиев Захретдин абый Шәкүрә апаның Сафа кызы икәнлеген белде (кушаматлары "бака" булган), Балтачка (Юлсубино) кияүгә чыкканлыгын, ире чехотка авыруыннан үлгәнлеген хәбәр итте. Шулай ук туган нигезләре кайда булуын күрсәтте. Авылда Миләүшә Касыймованың җыйган истәлекләре буенча югарыдагы мәгълүматлар билгеле булды.

Шәкүрә әбинең Юлсубино (Балтач) авылына кияүгә чыккканлыгын белгәнгә күрә шул авыл мәктәбенең музей җитәкчесе Фәнис Кәримуллинга мөрәҗәгать иттем, укучылар белән әлеге уку йортына юнәлдек. Анда кунакта булганда Шәкүрә әбинең күптәннән вафат булганын белдек, балалары турында сорашкач, кызларының Балык Бистәсендә һәм Биектау авылында яшәгәнлеге ачыкланды. Соңрак Шәкүрә әбинең Түбән Тегермәнлектә яшәгән оныгы бик күп истәлекләре белән уртаклашты. Мәктәпнең диварларында Бөек Ватан сугышында катнашкан исемлек тә Шәкүрә әбинең исеме дә урын алган.

Шәкүрә әби документларда 1921 елда туган дип язылган. "Үзен гел 1919 нчы елгы дип әйтә иде"-дип искә ала аның Түбән Тегермәнлектә яшәүче оныгы Гөлнара Мөбәрәкшина. Чынлап та архив документлары Шәкүрә әбинең 1919 елгы икәнлеген раслый.. Ике елга соң чыккан була Шәкүрә әби пенсиягә. Кайсыдыр чиновникның тупас ялгышы авылдашымны 2 ел буе коммунизм төзүдә өстәмә эшләткән булып чыга. Шәкүрә әби 3 яшендә әнидән калган. Әтисе яңадан өйләнгән. Ул хатынның балалары булмагач

атасы Әбиемә 7 яшь булганда яңадан өйләнә. Үги әнисе бик кырыс булган. Әтисе уртача хәлле кеше булган.

Ленинградка эшкә дип авылдан китә. Анда заводка эшкә урнаша. Сугыш башлангач, боларны окоп казырга дип шәһәр читенә алып китәләр. Окоп казыганда аларны немец самолетлары бомбага тотып китә. “Шунда минем әбиемнең аяклары яралана, ул аңын җуя”, -ди Гөлнара. Уянып китсә, немец солдатлары килә - үлмәгәннәрне җыялар, яраланганнарны үтереп баралар. “Әбиемә дә чират җитә. Шунда бер немец мылтыгын тери әбиемә, ул ялвара башлый”,-ди Гөлнара. Оныгының бу сүзләрне сөйләгәндә күзләре мөлдерәп килде.... Немецлар җәлләп аны носилкаларга салып үзләре белән алып китәләр. Аякларын дәвалыйлар. Шуннан соң аларны концлагерьларгә озаталар. Шәкүрә әби сөйләве буенча 5 илдә булган. Кайсы илләр икәнлеген генә әллә белмәгән, әллә әйтмәгән, ансын хәзер белмибез инде. Немецларның төрлесе була иде дип сөйләгән авылдашым балаларына. Гөлнара ул кечкенә булгангадыр инде, ул бик җентекләп сөйләргә яратмаган. Гомумән алганда да татар хатын-кызлары тормыш авырлыклары турында сөйләргә яратмаган бит ул элек. Биргәненә шөкер дип яшәгән.

Лагерьда булганда Шәкүрә башка әсирләр кебек үк немец солдатларына киемнәр теккән. “Ашарга юк, бәрәңге кабыгы да ашадык дия иде. Шуңа күрә ул һәр нәрсәнең кадерен белә иде һәм безгә дә шуңа өйрәтә иде”,-дип искә ала кызы Балык Бистәсендә яшәгән кызы Фирдәүсә.

“Әбием чиста, пөхтә, тырыш, батыр, кешелекле иде. Нинди генә киңәш сорап килсәң дә, җавабы таба иде, булдыра алганча булыша иде”-монсы инде Гөлнара истәлекләре. Русча, хәтта немецча да әзрәк сөйләшә белгән Шәкүрә әби. Әсирлектә аларны бер җирдән икенче җиргә вагоннарда төяп йөрткәннәр. Бер сөйләвендә “ Без бер гаҗәеп матур күл буенда тордык. Шул күлнең суы көндез күтәрелә, ә төнлә суы китә. Суы киткәч ай яктысында ялтыр – йолтыр балыклар кала яр буенда. Безнең һәр төнне, берничә хатын кызны, шул балыкларны җыярга чыгаралар. Без ул балыкларны күлмәк итәкләренә җыеп алып киләбез. Ул чагында без дә ач, сакчы немецлар да ач. Шул балыклардан безгә дә өлеш чыгаралар иде... Кайбер вакытта алар белән бер учак янында утырып шул табигать ризыгы белән сыйлана идек ”,-ди Шәкүрә.

Тарихта белгәнебезчә фашистлар әсирләрнең кулларына номер суга торган булганнар. Шәкүрә әбинең кулларында әлеге гомерлек саннар булмаган. “Тик менә җилкәләрендә, дүрт җирдә IVII римский саннар кебек сугылган иде. Нинди сызыклар булган дер инде, мин хәзер әйтә алмый. Иң актык илдә, Норвегиядә булган шуннан аларны Америка союзниклары коткарган”,-дип искә ала Гөлнара. Пленнан азат итеп 1 ай буе, трюм эчендә, кояш яктысы күрмичә, Фин култыгы аша чыкканнар. Анда бик күп кеше үлгән, күбесен үтергәннәр. Хатын кызларны көчләү очрагы булганга күрә аларның күбесе трюмга чыгарга да куркып аста ятканнар.

Шәкүрә әби сугыштан кайткач та, байтак еллар узенең лагерьләрдә булганын сөйләшеп йөрмәгән. Чөнки андый кешеләрне “враг народа” дигән сүзләр белән кире төрмәләргә япканнар. “Әбием бала чагы бик тә авыр

булган. Үги әнисе ел да диярлек бала тапкан, ул балалар туа барган, үлә барганнар. Әбиемә бөтен эш булган. Шул сабыйларны да гел аңа караткannар.

16 яшендә үги анасы Укмас авылына, 32 яшьлек бер иргә кияүгә бирә. Аннан ул качып кайта. Шулчак аны атасы бик каты кыйный. Ул әбисе янына төшеп китеп, аннан әзрәк акча алып, авылдан Ленинградка кача.

Анда аның яше тулмаган дип бер чәчәкләр үстерә торган теплицага эшкә алалар, ә инде яше тулгач завод цехына эшкә урнаштыралар.

Укуның ни өчен кирәклеген ул үзенчә аңлата иде. Әбием кирәк чагында иркәли дә белә, кирәк чагында әрли дә белә иде. Ул чиста, пөхтә кеше. Һәрнәрсәнең кадерен белә. Аның өе гел чиста, җыелган, чәе гел кайнап тора. Кул эшләрен: бәйләү, тегү, чигүне бик оста башкара иде. Үзенә күлмәкләр, алъяпкычлар тегә, калган кечкенә кисәкләрдән киезләр тегә иде. Оста итеп ямаулыклар ямый. Гомере буе шәл бәйләде. Кешегә җеп эрләп бирә иде. Аның шикелле бияләйләр, носкилар бәйләүче кешене минем хәзер дә күргәнем юк. Тәмле итеп ашлар, камыр ашлары пешерә иде. Көченнән килгәнен үзе эшләде. Бәрәңгесен, яшелчәсен үстерде. Алмагачларны, җиләк куаклары ел саен бирделәр. Тавык – чебешен үстерде.

Безнең кечкенә чагында ипи список буенча иде, аңа ярты буханка ипи тия иде. Шул чагында әби ашарга пешерә иде дә, ашаганда әйтә иде. “Бәрәңге, ашыңны күп итеп кап, ә ипине әз генә кап” – дия иде. Ачлыкнынң нәрсә икәнен ул бик белә, шуңа күрә валчыкларны да әрәм итми.

Бишенче сыйныфтамы, әллә алтынчыдамы, хәтерләмим инде мин мәктәптә, укытучы апа Роза Аглеевнага әбиемнең сугышта булганлыгымы әйтеп салдым. Шулчак ул әбиемне мәктәпкә чакырды. Әбиемнең башта барасы килмәде, ә аннан соң ул килде. Безнең сыйныфта ачык дәрес булды. Әбием безгә укырга кушты. Тәртипле балалар булып үсүебезне теләде, барыбызга да саулык теләде, сугышлар бүтән булмасын дип, елады. Безне сыйныф белән үзенә кунакка чакырда.

Әбием тынычлык яратты, ә без күп, шуңа күрә ул әзрәк үз өендә, әзрәк бездә яшәде.

Телевизор карага яратмый иде, радио тыңлады. 5 вакыт намазын укыды, уразасын тотты. Күп догалар белә иде. Берничәсен безгә дә өйрәтте.

Күршеләргә бик кешелекле, ярдәмчел кеше иде. Сугыш турында сөйләргә яратмады”,-дип сөйләп бетерде Гөлнара апа үзенең истәлекләРен.

Биектау авылында яшәүче олы кызы Нәсимә апа әнисе турында шактый гына мәгълүматлар бирде. Шәкүрә әбине ул, сугыш турында, лагерьда булганы турында сөйләргә яратмый иде ди. “Сорау бирсәң җавап бирә, әмма искә төшереп сөйләп утырмый иде” дип искә алды. Нәсимә апа: “Әни бик күпне күргән кеше” дип күз яшьләре белән искә алды. “ Сугыш башлангач аларны окоплар казырга җибәрәләр шунда бик каты яралана ул. Әнинең куллары 9 –11 җирдән тегелгән иде. Яра эзләре бик зур иде. 4 тәүлек аңсыз ята. Шуннан соң аларны Норвегия солдатлары “җыеп” алалар. Әнинең аяк куллары яраланган була. 11 ай буе аны госпитальләрдә дәвалыйлар. Шул 11 ай буе ул урын өстендә ята. Шуннан терелеп чыккач, аны кием тегә торган

җиргә җибәрәләр.” Бик ач була идек дип” искә ала иде әни. “Туңмас өчен кочаклашып йоклаган иптәшләр уянганда үлгән була иделәр”. Юка салам өстендә йоклаганнар алар, саламны бетләр генә күтәреп тора иде дип әйтә иде әни. Немец солдатлары чүплекләрне түккәнне генә көтеп торганнар, шуннан соң эшләргә алып чыкканда, шунда барып эзләнеп бәрәңге кабыкларын ашаганнар. Үлгән мәчегә кадәр ашаганнар алар. Әни гомер буе халык дошманы итеп танырлар дип куркып яшәде, аның кайтканда чемоданын урлыйлар, ә барлык документлары да шунда була. Туган авылына 1946 елда кайта”- дип сөйләде Нәсимә апа.

Нинди язмыш... Авыр тормыш... Кечкенә чакта кыз баланың әнисез калуы, үги ана, өй тулы үги наныйлар, репрессия еллары, көчләп кияүгә биргәннән соң качып кайту.... Аннары газиз атасы шуның өчен кыйный да әле. Әнисенең әнисе акча биреп Ленинградка юнәлеп бәхет эзләп чыгып киткән җирдән әсирлеккә эләгеп тәмугтан исән-сау кайту. Формалы кешеләр килер дип куркып яшәү. Чиновникларның ялгышлыгы аркасында ике елга соңрак пенсиягә чыгу. Шул ук бюрократизм аркасында тишле булган Германиянең әсирләргә биргән компенсациясендә ала алмау... Болар барысы да гади татар авылы кызына төшә. Шундый зур авырлыклар кичерсә дә гомерендә зарланмый, сабыр итеп яши Шәкүрә әби. Татар-мөселман хатыннарына хас булган билге бу. Әлеге мәкалә, эзләнү эше дога булып ирешсен иде. Ә Шәкүрә әбинең исеме авылыбыз тарихында мәңгеләштерелде.

ИЛФАР ГАБДРАХМАНОВ

ЮГАРЫ ТЕГЕРМӘНЛЕК АВЫЛЫ

